Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы Советы
# КАРАРЫ

2020 елның 23 октябре 14№

Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә турында» 63 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә турында» 63 номерлы карарына (алга таба - Нигезләмә) (2017.15.11, 131№; 2017.04.08, 115№; 2018. 15.11, 196№; 2019.12.04, 232№; 2009.25.10, 269№; 2020.19.03, 296№; 2020.28.08, 319№ үзгәртүләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Нигезләмәнең 8 бүлегендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;»

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин